СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш. Маннура, д.72 а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш. Маннур ур., 72 а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 1-41

Карар
29.04.2019 ел

“Олыяз авыл җирлеге Советының2018
елның 11 апрелендәге 1-31 санлы карары
белән расланган “Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл
җирлеге”муниципаль берәмлегетерриториясен
төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында”Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Олыяз
авыл җирлеге Советы карары турында

“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ санлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Мамадыш районы прокуратурасының 2019 елның 26 февралендәге тәкъдимнәре, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципальрайоны Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 санлыкарары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясентөзекләндерү кагыйдәләренә(17.09.2018 ел, 2-35 нче санлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Кагыйдәләрнең 2 бүлегенең 13 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 56 пунктбелән тулыландырырга:

“ 56. Юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) һәм физик затлар Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үзләренең милкендә биләүдә яки кулланууда булган җир участокларындаСосновский балтырганынбетерү (юк итү), аннан арындыру, бетерү (юк итү) буенча мөстәкыйль рәвештәүз хисабына системалы чаралар үткәрергә тиеш, (Сосновский балтырганынбетерү (юк итү) буенча чаралар аларбөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганга кадәр үткәрелергә

тиеш)”.

1.2. Кагыйдәләрнең 3 бүлегендәге 26 нчы бүлекнең 171 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча белән тулыландырырга:

“Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үз милекләрендә булган җир кишәрлекләрендәбетерү (юк итү), буенча чаралар юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) һәм физик затларның үз акчалары хисабына мөстәкыйль рәвештә Сосновский балтырганыбөреленгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.”

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгына И.Я.Хаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Я.Хаев